وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№1 (98). 12-08-2011 / Рамазан – 1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мөселман яшьләренең I проектлар мәктәбе тәмамланды ▷3◁




Хәзерге җәмгыятьтә диндарлар ▷6◁



Идел буендагы ислам мәдәнияте үсешен өйрәнү ▷7◁

# "ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ АЛАРДАН ЧЫГУ ЮЛЛАРЫ"

## (Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизнең Мәккә шәһәрендә узган конференциядән алган тәэсирләре)



**Әссәләмүгаләйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһү!**

Июль аеның ахырында Согуд Гарәбстанында үткән "Ислам дөньясы: проблемалар һәм алардан чыгу юллары" конференциясендә катнашырга туры килде. Конференциягә йөз иллеләп зур галим - Тунистан, Мисырдан, Согуд Гарәбстаныннан, ислам мәркәзләреннән Диния нәзарәтләренең, университетларның җитәкчеләре җыелган иде. Шулай ук Пакыстаннан, Һиндстан, Англия, Америка, Бразилия, бөтен Европа илләреннән, Австралиядән вәкилләр бар иде.

Әлеге конференциянең төп максаты - хәзерге көндә Ислам вәзгыяте, аңа бәйле проблемалар һәм алардан чыгу юлларын ачыктан-ачык уртага салып сөйләшүдән гыйбарәт иде.

Ни өчен хәзерге вакытта бөтен проблема Согуд Гарәбстанына барып тоташа? Конференциядә катнашучылар бөтен проблема Согуд Гарәбстанында, укырга китәләр һәм шәкертләрнең еш кына нинди гыйлем алып кайтуын контрольдә тотмыйлар, диләр. Шәкертләр төрле секталарга кереп, тегеннән-моннан алып, шушы радикаль сектант нәрсәне үзләренә сеңдерә башлый. Без инде хәзер шәкертләрне магистратурага гына җибәрәбез, ләкин шул кыска гына вакыт арасында да безгә бәдәви гореф-гадәтләрне алып кайталар, дип турыдан-туры ярып салдылар тунислар. Мисырлылар да күтәрелде, Европа мөселманнары да шушы мәсьәләгә кушылды. Сез контрольдә тотмыйсыз яки контрольдә тотып та, махсус эшлисез, диләр.

Моңарчы Татарстанда гына шундый проблемалар, шундый вәзгыять дип уйлый идек, бактың исә, бөтен Россиядә, хәтта Европада да шул, хәтта Африкада да шул, Согуд Гарәбстанының үзендә дә шул - сектантлыкка каршы көрәш икән. Согуд Гарәбстанында кайчандыр нык әзерлекле кадрлар укытып чыгардык һәм бөтен җирдә әлеге кадрлар эшсез калды.

Хәзерге вакытта аларның үзләрендә дә проблемалар барлыкка килә башлады. Шартлатулар, фетнәләр... Бездә ничек бара, анда да шундый фетнәләр башланды, ләкин анда җәзасы безнең дәүләтнеке кебек кенә түгел - үлем хөкеменә тарталар. Ягъни шуны әйтсәсе килә: бүгенге көндәге проблемалар бөтен дөнья масштабында бара! Нинди проблема икән соң ул исламда секталарның барлыкка килүе? Боларның барысына да конференциядә җавап табылды.

Кыскасы, шушы бозыклык, беренче чиратта, наданлык, икенче чиратта, ялкаулыктан килеп чыга. Мәсәлән, Коръәнне укыганнар, аять-хәдисләрне ятлаганнар, ләкин аларны тормышта куллана алмыйлар. Ни өчен? Чөнки гыйлем һәм ятлау икесе ике нәрсә!

"Аллаһы Тәгалә юлына чакырганда, хикмәт белән чакыр һәм бик матур вәгазь белән чакыр". Безнең исламда да шундый нәрсә пәйда булды - шәрехләүсез, аңлатусыз, ятлаганны гына сөйләп бирү. Коръәннән, хәдистән алган, ләкин аңлата алмый, чөнки ул аны сүзен-сүзгә ятлаган, практикада кулланганда хикмәт юк. Менә шуның өстендә эшләргә кирәк тә инде. Конференциянең дә төп мәгънәсе шунда иде.

Гыйлемне бишектән алып, ләхеткәчә алыгыз, диләр бит. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә әйткән: "Минем сәхабәләрем бик күп, шулай да һәр яңа гасыр башында динне аңлатучы яңа кеше киләчәк". Чөнки, мәсәлән, теге яңа гасырның башындагы татар теле белән, хәзерге тел арасында бик зур аерма бар. Бүгенге көн галиме гыйлемне заман теле белән аңлатырга тиеш, шул чакта, шул вакытта гына ул аны тыңлаучыга барып ирештерәчәк.

Намаз уку, ураза тоту, хаҗга бару, зәкят бирү - бу әле мөселманлыкның бердәнбер күрсәткече түгел. Мөселман әдәп, әхлак ягыннан да, тирә-юньдәгеләр белән мөгаләмәсе, яшәү рәвеше һәм башка күркәм сыйфатлары белән дә үрнәк булырга тиеш. Әйтик, монафыйкларның башында торган Мәдинә шәһәрендәге Абдулла ибне Сәлам намазын да укый, мәчетен дә төзи, ләкин барысы да - бары күз буяу өчен генә. Мөхәммәд (с.г.в.) дә шуның өчен дә үз куллары белән аның мәчетен яндыра. Шулай да гомеренең ахырында Абдулла ибне Сәлам дә үкенә һәм ихластан Исламга килә.

Син Аллаһы Тәгаләне күргән кебек яисә Аллаһы Тәгалә сиңа карап торган кебек Аны тоярга тиешсең. Ул очракта бер-береңә каты сүз әйтә алмыйсың, Коръәндәгечә яшәргә тырышасың.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*



**Татарстан Республикасы Президенты**

## УКАЗЫ

### Мөселман бәйрәмнәрен үткәрү турында

**2011 елда Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен бәйрәм итү турында "Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында" Татарстан Республикасы Законының 1 нче статьясы нигезендә карар бирәм:**

**1. Татарстан Республикасында: ай календаре һәм урнашкан традицияләр нигезендә 2011 елның 30 августын Ураза бәйрәме башлануга туры килә торган көн;**

**ай календаре һәм урнашкан традицияләр нигезендә 2011 елның 6 ноябрен Корбан бәйрәме башлануга туры килә торган көн дип билгеләргә.**

**2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.**

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

**Казан, Кремль 2011 ел, 1 август**

# ИЗГЕ РАМАЗАН АЕ




**Бу көннәрдә бөтен мөселман дөньясы, шул исәптән Россия мөселманнары да, ай календаре буенча 9 нчы ай - изге Рамазан аен каршы алды. Рамазан аенда бөтен дөнья мөселманнары да ураза тота. Мөселманнарның уразасы христиан динендәге посттан аерыла.**

Пост тотканда, христианнар хайван чыганаклы ризыкларны ашауны чикли. Ислам динендә исә мөселманнар таң вакытыннан алып кояш баеганчыга кадәр һәртөрле ризыктан, эчемлектән һәм җенси якынлыктан тыелып торырга тиеш. Ураза тоту изге Рамазан аенда 30 (29) көн дәвам итә. Рамазан ае мөселман календарендa үзенчәлекле ай булып санала. Бу ай турында Изге Коръәндә болай дип язылган: "Рамазан ае - бик шәриф ай, ул айда Аллаһы Тәгаләдән кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидиятне ачык бәян кылучы Коръән иңдерелде. Сезләрдән Рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, рузә тотсын!" (2:185, "Ногмани тәфсире"ннән). Рамазан ае - Коръән иңдерелгән ай. Нәкъ менә шушы айда пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) Коръәни-Кәримнең беренче аятьләре белән таныша. Әлеге айда ул Аллаһы Тәгаләнең беренче сүзләрен ишетә. Күп гасырлар дәверендә мөселманнар Рамазан аенда ураза тотып киләләр.

Ураза аендагы барлык сынаулар да кешегә үзендә ике төрле теләк-ихтыярны (дәртне) тыярга ярдәм итә: кешене хайван дәрәҗәсенә кадәр төшерүче ризыкка комсызлык, чаманы белмәүне һәм һәртөрле омтылыш-шәһвәтне. Димәк, ураза кешенең ихтыярын тәрбияләргә чакыра. Кеше үзенең теләк-омтылышларының колы булырга түгел, ә аларны үзенә буйсындырырга тиеш. Икенче яктан караганда, ураза тоту мохтаҗлыкта яшәүчеләрнең хәленә керергә ярдәм итә. Ай дәвамында ачлык һәм сусау хисе кичергәндә, әлбәттә, ураза тотучыга гел шундый шартларда яшәүчеләрнең хәле аңлашыла. Шуңа күрә Рамазан ахырында фитыр сәдакасы бирелү дә очраклылык түгел. Әлеге сәдака мохтаҗлар тамакларын туйдырсын, табигый ихтыяҗларын үти алсын өчен бирелә. Нәкъ менә шушы айда хәйриячелек, якыннарыбызга мәхәббәт һәм теләктәшлек фикере үткәрелә.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# "ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ АЛАРДАН ЧЫГУ ЮЛЛАРЫ"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Коръән һәм хәдисне ни өчен ятлыйлар? Дөньяда, тормышта кулланыр өчен. Коръән дә, сөннәт тә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) тормышы да бу дөньяда хәрамга керешмичә, дөрес итеп яшәргә өйрәтә.

Дөньяви гыйлем белән дини гыйлем бергә булган вакытта гына кеше бу дөньяда тиешенчә яши ала. Әйтик, мөселман булып, инженер булуың хәерлерәкме яки инде мөселман булуың гына хәерлерәкме? Мөселман булып, зур проектлар ясавың хәерлерәкме яки мөселман булып надан булып калуың хәерлерәкме? Бүгенге көндә сәләфи-ваһһабчылык кешене дөньяви гыйлеменнән арындырып, һаман урта гасырларда гына калдырмакчы була. Мәсәлән, менә гыйлем әһелләре урта гасырларга чакыра, идәнгә утырып ашарга өнди һ.б.

Әлеге конференциянең дә, безнең җыйналуыбызның да сәбәбе шуннан гыйбарәт иде - гыйлемнең кирәклеге. Коръән дә, сөннәт тә, дөньяви һәм дини гыйлем дә - бүгенге көндә хәрамга керешмичә, уңайлы тормышта яшәргә рөхсәт итә торган Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте. Хәдисне ятлап, бер-берең кычкырышып, мактанышып йөрү дөрес түгел ул. Шушы мәсьәләне уртага салып сөйләшеп, барысын да аңлаштык. Ислам дине хәдис-Коръәнне яттан белергә чакырмый, ул дини һәм дөньяви гыйлем алып, аны тиешле вакытта, кирәкле җирдә, файдалы урында куллана белергә, һәркемгә файда китерә торган гыйлем җыярга чакыра.

Сөннәт гамәлләренә килгәндә, намаз уку - сөннәт, тәсбих тарту - сөннәт. Кайсы кулайрак? Һәркайсының үз урыны бар!

Бүгенге көндә әле һаман да намаз уку-укымау, сөннәт-сөннәт булмау турында бәхәсләшәбез. Инде боларның барысына да нокта куяр вакыт җиткәндер. Безгә бүген, иң беренче нәүбәттә, әдәп җитми! Шул ук мәчеткә кергәндә, ни өчен яланаяк керәбез? Алай гына да түгел, Аллаһы Тәгалә янына шортик-майкадан керергә җөрьәт итәбез әле без! Югыйсә, берәр зур кеше белән эшлекле очрашуга барганда, без костюм-чалбарны кияргә, галстук тагарга онытмыйбыз.

Аллаһы Тәгалә йортына барганда, рәтле киемнән генә түгел, чиста-пакь киемнән киенү дә зарур. Безнең өчен Аллаһы Тәгалә белән очрашу бәйрәм булырга тиеш. Сугышта катнашкан бабайлар орден-медальләрен тагып баралар. Алардан үрнәк алу кирәк!

Саный китсәң, безгә әле әдәп-әхлакка өйрәнәсе дә, өйрәнәсе! Шуңа да хәдисләрне, Коръән аятьләрен аңлап, тормышта адым саен кулланып, шуның белән бербөтен булып яшәргә кирәк!

Бер җирлектәге халыкның ялкаулык аркасында килеп чыккан гореф-гадәте ислам динендәге сөннәт дип алып кайтып, мондагы халыкка, бигрәк тә мәдәниятле халыкка тагарга тырышу - бүгенге көндәге проблема. Наданлык һәм ялкаулык! Хәдис, Коръәннән аять ятлап утырып кына булмый - шул ятланган аятьхәдисләр бүгенге көндә кулланылырга яраклы гыйлем булырга тиеш. Синең намазың - ашарга тиешле ризык кебек, ягъни ашамыйча яши алмыйбыз бит без, шуның кебек намаз укымыйча да яши алмыйбыз, ураза тотмыйча да яши алмыйбыз. Болар безнең рухи азыгыбызга әйләнергә тиешләр. Ләкин бу гына мөселманлыкның күрсәткече түгел, иң мөһиме - күңел чисталыгы, синең тирәюньдәгеләргә хәерле мөгамәләң! Шуны онытмасак иде. Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгаләгә, пәйгамбәребез Мөхәммәд сәләллаһу галәйһи вәсәлламгә күңелләребезнең түреннән чыккан салават шәрифләребез булса иде.

## Казан мэры унҗиденче елын ураза тота

***Казан мэры Илсур Метшин 17 ел рәттән ураза тота һәм башкаларга да киңәш итә. Аның үрнәгенә инде 13 яшьлек кызы да ияргән. Дин тоткан кеше начарлыктан ерак тора, дигән фикердә шәһәр башлыгы. Метшин яшьләрнең dингә тартылуын да уңай күренеш дип саный.***

"Төгәл генә әйтә алмыйм, унҗиденче ел рәттән ураза тотамдыр, - ди Илсур Метшин kzn.ru порталында узган онлайн-конференция барышында. - Уразаны тормыш иптәшем дә, олы улым да тота. Быел кызыбыз да сөенderдерә. Аңа 13 яшь, ул беренче адымын ясады".

Ураза тотуның мәгънәсе үз эченә иман ныклыгын, рухи үсешне, яшәү рәвешенә анализ ясауны күз алдында тота. Шәһәр мэры сүзләренә караганда, аның командасында дини традицияләрне үтәгән кешеләр шактый.

"Казанның, спорт башкаласы булуыннан тыш, Россиянең рухи башкаласы булуын да теләр идем, - дигән өметен белдерде Илсур Рәис улы. - Тынычлык, милли килешү - шәһәребезнең төп символы".

Әлегә ураза тотмаучыларга шәһәр башлыгы рухи яктан чистарынуга беренче адымнарын ясап, берничә көн ураза тотып карарга киңәш итте.

**tatartime.com сайтыннан алынды**

## КФУда мөселман илләре һәм ислам икътисады белгечләрен әзерли башлаячаклар

***КФУда мөселман илләре һәм ислам икътисады белгечләрен әзерли башлаячаклар. Вузның Көнчыгышны өйрәнү институтында узган ел ачылган төбәк һәм ислам кафедрасы җитәкчесе, профессор, икътисад фәннәре докторы Ренат Беккин: "Без санаулы белгечләр әзерләячәкбез", - дип белдерде.***

Ислам икътисады белгече фикеренчә, "Ике чит телне генә түгел, билгеле бер төбәк үзенчәлекләрен өйрәнгән белгечләр дәүләт хезмәтендә, дипломант булараk, коммерциядә һәм фәндә - бар җирдә кирәк. Федераль хөкүмәт КФУны ислам дөньясын өйрәнүгә һәм Россиянең мөселман илләре белән хезмәттәшлек алып баруына яраклы сыйфатлы белгечләр әзерләүче үзәк вуз итеп күрә".

Шушы көннәрдә вуз "чит ил төбәкләрен өйрәнү" юнәлешендә белгечләр әзерләүгә лицензия алды. Әлегә укырга теләүчеләрне контракт нигезендә җыялар, августта сигездән алып унбишкә кадәр бюджет урыны барлыкка киләчәк.

Биредә ныклап инглиз телен, ким дигәндә бер шәрык телен укытуга һәм мөселман илләрен, ислам икътисадын өйрәтүгә басым ясаячаклар.

**ksu.ru сайтыннан алынды**

## Республикакүләм ифтар узачак!

**26 августта башкалабызда беренче тапкыр республика күләмендә авыз ачу мәҗлесе оештырыла. Бу чарада меңнән артык кеше катнашыр, дип көтелә. "Рамазан - 2011" республика ифтарын Татарстан Диния нәзарәте Президент аппараты, хөкүмәт, Казан мэриясе белән берлектә оештыра.**

Ифтарның программасына килгәндә исә, мәҗлескә чакыру алучылар кичке җидедә Кол Шәриф мәчетенә җыелачак. Анда Татарстан мөфтие Илдус Фәиз чыгыш ясар дип көтелә. 19.54 сәгатьтә авыз ачып, ахшам намазы укыгач, Ярминкә мәйданында ифтар мәҗлесе башланып китәчәк.

Шулай итеп, Татарстан тарихында беренче тапкыр дәүләт дәрәҗәсендә ифтар ашы оештырыла.

# ИЗГЕ РАМАЗАН АЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Рамазан аенда мөселманнар шулай ук үзенчәлекле намаз - тәравих намазын укыйлар. Әлеге намаз бөтен дөньядагы мәчетләрдә тантаналы рәвештә укыла.

Уразаның рәсми ягыннан тыш (ризык, судан, җенси якынлыктан тыелып тору), рухи ягы да бар. Ай дәвамында ураза тотучылар ризыктан, бер тамчы судан гына түгел, төрле яман сүз, гайбәт сөйләүдән, начар уй-ниятләрдән дә тыелып тора.

Изге Рамазан аенда Хак Тәгаләгә ышанучылар саваплы эшләрне күбрәк башкаралар. Якыннарының, туганнарының, күршеләренең хәлен беләләр.

Изге китаплар укыйлар. Аларга салынган белемнәрнең тирәнлеген аңларга тырышалар. Шулай ук кирәкмәгән файдасыз эшләрдә катнашмаска, тормышның һәр мизгелендә саваплы эшләр башкарырга омтылалар. Бүген күп кешеләр: "Ни өчен шулкадәр сынаулар үтәргә кирәк?" – дип сорый.

Әлеге сорауга җавап бирү өчен ураза тотуның чистарынуга китергәнлеген аңларга кирәк. Ислам дине дөньялыктан, җирдәге шатлыклардан баш тартмый. Ахирәттә дә, бу дөньяда да тулы канлы тормыш белән яшәү динебез тарафыннан хуплана. Әмма шунысын да аңлау мөһим: әгәр дә кеше үз хис-тойгыларының, җирдәге ләззәтләрнең корбаны булса, кеше бәхете дигән төшенчә сорау астында кала. Кешенең эчке дөньясы тулысынча ирекле булганда, ул җирдәге ләззәтләргә, теләк-ихтыярларына бәйле булмаган вакытта, кеше тагын да гармониялерәк тормыш алып бара. Һәм моңа ирешүдә ураза тоту ярдәм итә. Ураза тоту кешеләрне дуслаштыра, чөнки бу вакытта ярлылар белән байлар арасындагы социаль тигезсезлек юкка чыга. Төрле дәрәҗәдәге кешеләр ачлык кичергәндә, бай кешеләрнең күзләре ачыла. Алар ярлыларның һәм мохтаҗларның ничек яшәвен аңлый. Бүген безнең барыбызга да мондый сабак файдалы булыр. Чөнки күбебез җитеш тормышта яши, ягъни элеккеге буыннар белән чагыштырганда без ачлыкның ни икәнен белмибез. Шулай да планетабызда ач-ялангач яшәүчеләр җитәрлек.

Мөселманнар үзләренең дини тормышларын кояшныкыннан кыскарак булган ай календаре буенча алып бара. Ел саен Рамазан ае 11-12 көнгә алга күчеп бара. Быел мөселманнарның уразасы август аена туры килде, ягъни алар уразаны җәйге озын көннәрдә тотарга тиеш булды. Шартлар авыр кебек тоелса да, мөселманнар уразы тоту җиңел бирелә, диләр. Кайвакытта диета тоту кыен була. Әмма ураза тоту турында сүз барганда, Ходайга ышанучыларның әллә кайдан яңа көчләре, куәт чыганаклары барлыкка килә. Шуңа күрә алар уразаны җиңел тота. Быел да ураза тотучыларга шул көчләр ярдәм итәр, дип ышанабыз. Рамазан ае, һәрвакыттагыча, саваплы эшләр, якыннарыбыз турында кайгырту, күрше-тирәдә яшәүчеләргә мәхәббәт һәм теләктәшлек ае булсын иде, дигән теләктә калабыз.

**Нияз САБИРҖАНОВ.**

## "Игелекле галәм"

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән "Яңа гасыр" радиосы 24 августка "Игелекле галәм" исемле радиомарафон әзерли.**

Яңәшәбездә матур-матур киемнәргә, тәмле-тәмле ризыкларга кызыгып яшәүче балалар бар! Алар үзләрен кимсетелгән итеп түгел, кирәкле дип тойсын өчен талпыныш язу кирәк!

Марафон көнендә җыелган акча республикабызның аз керемле гаиләләренә азык-төлек алуга тотылачак! Бүләкләр Ураза бәйрәме көннәрендә тапшырылачак. Мохтаҗ гаиләләр исемлеге ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгыннан алынды.

Билгеле, бер марафон белән генә бар гаиләләргә дә ярдәм итеп булмаячак, әмма әлеге гамәлне башкалар да күтәреп алырга, дәвам итәргә мөмкин.

24 август көнне иртәнге сәгать җидедән башлап, 12 сәгать дәвамында "Яңа гасыр" радиосы эфирында дин әһелләре, иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр, төрле оешма җитәкчеләре, хәйриячеләр, мәдәният әһелләре, газета-журнал битләрендә дини сәхифәләрне алып баручы журналистлар булачак. Шулай ук изге ниятә булган тыңлаучылар да эфир аша үз фикерләрен җиткерә алачак.

Һәркем, радиомарафонда катнашып, үз өлешен кертә ала.

**"Игелекле галәм" радиомарафонының исәп-хисап счёты:**

**Централизованная религиозная организация - Духовное управление мусульман Республики Татарстан**
**Адрес: 420111, г. Казань, ул. Лобачевского, 6/27**
**р/счет 40703810900028001187**
**в ОАО "АК БАРС" БАНК**
**БИК 049205805,**
**к/с 30101810000000000805**
**ОКОНХ 98700**
**ИНН 1655032502 КПП 165501001**
**ОКПО 27828170**
**"Радиомарафон"**

***Галәмебезне игелек нуры белән балкытыйк, гамәл дәфтәребезгә күркәм сәхифә языйк!***

# МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕНЕҢ I ПРОЕКТЛАР МӘКТӘБЕ ТӘМАМЛАНДЫ

***Сәләтле мөселман яшьләренең "Алтын урта" лагере - I проектлар мәктәбе тәмамланды. Болгарда үткән әлеге чарада кырыкка якын мөселман яшьләре катнашты.***

Проектлар мәктәбе беренче тапкыр үткәрелсә дә, катнашучыларның сүзенә караганда, югары дәрәҗәдә узган. Чарадан соң үткәрелгән сораштыру "Проектлар мәктәбе үз максатына иреште", "дәвамын көтәм", "беренче тапкыр булса да, яхшы үтте" диючеләрнең күп булуын ачыклады.

Лагерьның программасы да шактый тулы һәм файдалы иде. Мөселман яшьләре мәгънәле һәм югары дәрәҗәдә үткән остаханә, тренингларда катнашты, фикерне проект итеп формалаштыру, проектны чынга ашыру, үз өстеңдә эшләү, лидерлык сәләтен үстерү, җәмәгатьчелек белән эшләү алымнарына өйрәнде.

РИУның икътисад фәннәре укытучысы Галим Вахитов һәм Россия ислам икътисады үзәге җитәкчесе урынбасары Сираҗетдин Нәбиев "Бизнес-план төзү. Гамәли аспектлар" темасына остаханә үткәрде.

Галим әфәнде яшьләрне глобаль киңлектә фикер йөртергә, Сираҗетдин әфәнде исә эшкә алыныр алдыннан ниятне дөрес ачыкларга чакырды.

Психолог Рамил Гарифуллин белән очрашу яшьләр күңеленә аеруча хуш килде. Җәмәгатьчелек белән эшләү, манипуляцияләргә бирелмәү, секталарны бер караштан ачыклый белү, чыгыш ясаганда каушамау һәм башка күп мәсьәләләр каралды. Рамил әфәнденең чыгыш башында әйткән сүзләре дә лекциянең максатын ачып бирде: "Сез бу очрашуны гомергә истә калдырырга тиеш", - диде ул.

Казан федераль университетының юридик факультеты деканы урынбасары Илсур Салихов "Эшлекле сөйләшүләр алып баруның теория һәм гамәли ягы" темасын ачыклады. Ул динне фәнни яктан ачты һәм дөньяви этика белән исламның бәйләнешен күрсәтте.

"Шамил" мәчете имам-хатыйбы, казый Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин белән җомга намазы Болгарның Җәмигъ мәчетендә укылды.

Икътисад фәннәре кандидаты, Казан дәүләт финанс-икътисад институты һәм MBA программасы доценты Аделия Павлова "XXI гасырда лидерлык" дигән темага остаханә үткәрде. Ул кешеләрнең лидерлыкка карата мөнәсәбәтләре, лидерлык сәләте, аның холык белән бәйләнеше турында сөйләде. "XXI гасыр лидерлыгы - ул төркем лидерлыгы", - дип билгеләп үтте Аделия ханым.



"Татэнергосбыт" оешмасы җитәкчесе Марат Миңлебаев "Ислам һәм эшлекле шәхес этикасы" темасына остаханә үткәрде. Ул уңышка ирешү формуласын ачып бирде, "Гыйбадәт кыл һәм эшлә" сүзләре яшьләрнең төп лозунгы булырга тиешлеген әйтте һәм аларны Аллаһы Тәгаләгә, гаделлек принципларына тугры калып, тырышып эшләргә чакырды.

Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз белән яшьләр Идел ярында "Булгария" фаҗигасендә вафат булганнар рухына дога кылды.

Проектлар мәктәбенә күп яшьләр әзер проект белән килгән иде. Шулай да килгәч кенә эшкә тотынучылар да булды. Ничек кенә булмасын, нәтиҗәдә һәр катнашучының игътибарга лаеклы үз проекты бар иде.

Мөселман яшьләре үз проектларының әһәмиятен аңлатып, аларны тәкъдим итте. Нәтиҗәдә, утызлап проект арасыннан иң уңышлы дип табылган бишесе сайлап алынды, авторларга истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Шул биш проект исемлегендә "Төбәкара Россиякүләм милли-мөселман ял һәм сәламәтләндерү лагере" проекты белән Гөлсәрия Нәбиуллина төркеме, "Мөселман яшьләренә татар теле нигезләрен өйрәтү" проекты белән Рамилә Майорова һәм Динара Мөбарәкҗанова, "Ислам дине - якты киләчәк" проекты, "Ялкын" журналында дини сәхифә булдыру һәм мәктәпләрдә дини түгәрәкләр ачу фикере белән Гөлфинур Хәбриева, Чулпан Гыйләҗиева, Чулпан Галиева, "Мөселманнарның мәшгульлек үзәге" проекты белән Арыслан Хәммәдиев һәм "Мәчетләрдә милли түгәрәкләр" проекты белән Марат Ризвановлар бар иде.

Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз барлык проектларны да янәдән карап чыгачакларын, уңышлы дип табылганнарын тормышка ашыруда ярдәм итәчәген искәртте. Диния нәзарәтенең мәгариф бүлеге җитәкчесе Вәлиулла хәзрәт Якупов проектларны брошюра итеп бастырырга тәкъдим итте.

Гомумән әйткәндә, I проектлар мәктәбе мөселман яшьләренең, күпләр уйлаганча, басынкы һәм пассив булмавын ачып бирде. "Алтын урта" сәләтле мөселман яшьләре лагеренда үз проектлары белән катнашучы яшьләр фикерләрен тормышка ашырырга әзер һәм җәмгыятькә файда китерү теләге белән яна.

Мәктәп укучылары үзләрендә дин түгәрәкләре оештырырга, "Мәхәллә бәйрәме" проектының авторы мәчетләрдә бәйрәм чараларын башларга, мөслимәләр өчен бию түгәрәге үткәрергә тәкъдим итүче кыз эшне үз кулына алырга, мөселманнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтү тәкъдиме белән чыккан егетләр әлеге эшне үзләре башлап җибәрергә әзер.

Чара ахырында үткәрелгән нәтиҗә сораштыруында Азнакай кызы Чулпан Галиева болай дип яза: "Минемчә, бу - бик уңышлы чара. Күп яшьләр яңа идеяләр белән янып йөри, әмма аларны тормышка ашыра алмый. Ә проектлар мәктәбе аларга үз сәләтләрен ачарга ярдәм итә. Киләчәктә мондый чараларны тагын да ешрак уздырырга кирәк".

Арчадан килгән Гөлфинур Хәбриева да рәхмәт сүзләрен күпләп әйтә. "Дүрт көн эчендә мин үзем өчен күп файдалы мәгълүмат тупладым, үземә кирәкле киңәшләр ишеттем. Шуны да әйтәсе килә: дүрт көн - бик аз вакыт, ләкин шул көннәр эчендә инде туганлашып беттек дияргә була. Китәсе дә килми", - ди Гөлфинур.

Проектлар мәктәбе әле моның белән тәмамланмаячак. Ел дәвамында проектлар чынга ашырылачак һәм киләсе елда яңа проектлар бәйгесе игълан ителеп, II проектлар мәктәбе оештырылачак.

**Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА.**
**azatliq.org сайтыннан алынды**

# БЕЗДӘ КӨН ДӘ – ИФТАР МӘҖЛЕСЕ

**Безнең "Болгар" мәчетендә шактый еллар (мәчет оешканнан бирле дип әйтеп була инде) авыз ачу мәҗлесләре оештырыла. Мәчет хисабыннан да, мөмкинчелеге булган кардәшләребез дә ярдәм итәләр.**

Бу - җәмәгатькә, авыр хәлдәгеләргә, мохтаҗларга, эшләү сәбәпле, өйләренә кайтып авыз ачарга вакытлары булмаучыларга булышу йөзеннән оештырылган ифтарлар. Быел да Рамазан ае күркәм генә башланып китте. Җәмәгатьнең куп булуы, ифтарга кешеләрнең күп килүе безне шатландыра, куандыра. Ел саен ифтарга безгә хәләл кафе ризыклар пешереп алып килә, үзебез дә пешерәбез. Аллаһы Тәгаләнең фарыз уразасы авыр вакытка туры килде. Озак вакыт тотабыз җәй көнендә. Ә ифтар мәҗлесләрен оештыру кешеләргә дә бер шатлык, үзебезгә дә бер әҗер-савап булыр, дип уйлыйм мин. Мәҗлесләргә утыздан алып алтмышка кадәр кеше килә. Мәчеткә Советлар вакытында ук, узган гасырның 1990 нчы елларында ук нигез салынган. Шул вакыттан бирле мәхәллә халкы тырышлыгы белән, җәмәгать белән бергәләп салынган бер мәчет бу. Монда мәхәллә халкы күп йөри, башка милләттәге дин кардәшләребез дә йөри, шулай да үзебезнең татар халкының даими йөрүе дә бермә-бер шатландыра.

Үзләре теләк белдереп, төрле көнне төрле кеше авыз ачтыра. Шулай итеп, килешеп эшләнә.

Вәгазьләрне компакт дискка яздырып тарату, халык белән тыгыз эшләү, җәй көннәрендә булып уза торган мөселман лагерьларын оештыру, укыту процессында катнашу, дини бәйрәмнәрне җәмәгать белән бердәм уздыру, догалар кылу - бу безнең ел әйләнәсе үтә торган, бер калыпка салынган традицияләр.

Вәгазьләр фәкать татар телендә үтә, халык белән аралашу да, уку-укыту процессы да татар телендә уза. Җомга намазында гына түгел, өйлә намазында да килгән халыкка вәгазь сөйләнелә. Боларның барысы да бездән генә тора димәс идем, монда бирегә йөри торган татар телен камил рәвештә белүче бабайларыбызәбиләребезнең хезмәте бик зур. Алар татар телендә аралаша һәм татар телендә аралашканны ярата. Элек-электән килгән безнең мәзһәбне бергә алып барабаз, безне күреп, яшьләр дә безгә кушыла.

Аллаһы Тәгалә ураза тотучыларга көчкуәт бирсен, сабырлык, түземлек белән, шатлык-куаныч белән тотып бетерергә Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсен. Инде Аллаһ Раббыбыз күңелләребезгә иман дигән байлыкны урнаштырган икән, шул иман дигән байлык ихласлык белән кушылып, мөселманнар арасында дус-тату мөнәсәбәт, үзебезнең тоткан мәсләгебез Әбү Хәнифә мәзһәбе юнәлешендә алып барсак иде. Аллаһы Тәгалә разый булырлык гамәл-гыйбадәтләребез, изге эшләребез дөнья тормышында күп булса иде дигән теләктә калам.

**Марсель хәзрәт САБИРОВ,**
**Казанның "Болгар" мәчете имамы**



# Зәкят бирү – фарыз гамәл

Благотворительный Фонд Закят

***Зәкят ул:***
***— Аллаһы Тәгаләнең әмере;***
***— җәмгыятьтәге байлар-фәкыйрьләр арасын төзәтүче, кардәшлек урнаштыручы күпер;***
***— байларны малга булган хирыслыктан, үз-үзеңне яратудан (эгоизмнан), ярлыларны көнчелек утыннан саклаучы калкан;***
***— мохтаҗлар өчен "ашыгыч ярдәм".***

Зәкят бирү өчен мөлкәтнең нисабка тулуы шарт. Бу байлык-мөлкәт билгеле бер күләмгә, ягъни нисабка җиткән очракта гына зәкят түлиләр дигән сүз. Быел Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан нисаб күләме 116200 сум дип билгеләнде. Шуның кырыктан бер өлеше (2,5 проценты) зәкят була ала. Ким дигәндә билгеле бер байлыгыгыз ел дәвамында 116200 сум тәшкил итә икән, шуңардан зәкят бирә аласыз.

**Нәрсә соң ул зәкят?**

Ислам дине биш нигездән тора: Аллаһы Тәгаләне тану һәм аның берлегенә ышану, намаз уку, зәкят түләү, ураза тоту, хаҗ кылу. Күргәнебезчә, намаздан соң Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөселманнарга фарыз итеп йөкләтелгән гамәлләрнең берсе - зәкят.

"Намаз укыгыз һәм зәкят түләгез", - дип язылган Коръән аятьләрендә. "Зәкят" сүзенең бер мәгънәсе "чистарыну, пакьләнү" булса, икенчесе - "үсеш". Зәкят биргән кешенең малы хәләл, пакь, үзе рухи үсештә була.

**Кемнәр бирә ала?**

Балигълык яшенә җиткән, үз акылындагы, ирекле, билгеле бер мөлкәткә (минимум нисабка) ия мөселманнар.

**Зәкятне нинди мөлкәттән түлиләр?**

– Акча берәмлекләреннән (алтын, көмеш).

– Сәүдә кеременнән.

– Маллардан, җыелган уңыштан, гомумән, кешенең минимум нисабтан арткан мөлкәтеннән.

**Кемнәргә бирелә?**

Нисаб кадәр мөлкәте булмаганнарга. Алар арасында авырулар, ятимнәр, ярлылар, мескеннәр, мосафирлар, бурычлылар, тол хатыннар һәм башкалар булырга мөмкин. Шулай ук аны билгеле бер зәкят җыючы оешма вәкилләренә, дин таратучыларга тапшырырга мөмкин.

**Фитыр сәдакасының иң аз күләме - 50 сум**

Фитыр - зәкятнең бер төре. Ул Шәүвәл аеның беренче көненә кадәр, ягъни гает намазы укылганчы бирелергә тиешле сәдака. Әгәр алданрак бирелә икән, гөнаһ юк.

**Фитырны күпме күләмдә бирергә?**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хәбәр иткәнчә, быел фитыр сәдакасының иң аз күләме бөртеклеләр бәясеннән чыгып санаганда - 50 сум; хөрмә җимеше бәясеннән исәпләгәндә - 100 сум; йөзем бәясеннән санаганда - 300 сум.

**Нәрсә ул "фидия"?**

Авыру яки өлкән яшьтә булулары сәбәпле ураза тота алмаучылар һәр көн өчен ким дигәндә йөз сум күләмендә фидия-сәдака бирә ала.

**Кемнәргә фитыр сәдакасы бирү мәҗбүри?**

Фитыр сәдакасы бирүнең мәҗбүри булуына дәлил Ибн Габбас тарафыннан җиткерелгән хәдистә аңлатыла: "Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) түләүне ураза тотучыларның үзләре тарафыннан әйтелгән артык сүзләрдән, дорфалыклардан арындыру һәм шулай ук мохтаҗларны туендыру (хәсрәтен уртаклашу, ярдәм итү) өчен фитыр сәдакасын фарыз иткән".

Икенче хәдистә Ибн Гомәрнең болай диюе хакында хәбәр ителә: "Аллаһының илчесе (Аллаһы Тәгалә аңа хәер-догасын иңдерсен) Ураза гаете көнне, бәйрәм намазына чыгар алдыннан, мөселман булган һәркемгә - колга һәм ирекле кешегә, ирләргә һәм хатын-кызларга, олысына һәм кечесенә - бер "са" финик яки арпа күләмендә сәдака өләшүне фарыз итә" (әл-Бохари).

Һәр мөселман фитыр сәдакасы бирергә бурычлы. Аллаһка шөкер, бүгенге көндә күпләребез бу сәдаканы бирерлек мөлкәткә ия.

**Сәдака кемнәргә бирелә?**

Зәкят, гошер кебек үк, мохтаҗларга, хәерчеләргә бирелә.

Фитыр сәдакасы алгач укыла торган дога:

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Әллаһүммә тәкаббәл фитратәһү үә сыямәһү үәстәҗиб дүгә'әһү үәгъфир зүнүбәһү үә әккид имәнәһү үә әксир әмүәләһү үә үәффикъһү галә хайри мәкасыйдиһ.

Мәгънәсе: "Әй, Аллаһы, (бирүченең) фитыр сәдакасын вә уразасын кабул кыл, догасын кабул кыл һәм гөнаһларын гафу кыл, вә дәһи аның иманын куәтле кыл, аның малларын арттыр һәм аны хәерле максатларына ирештер".

**Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ,**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" фонды җитәкчесе**

ИФТАР - 2011

# Изге айда - изге гамәлләр

- Рамазан ае башлангач, быел да һавалар үзгәрде, көннәр сүрелде. Ураза тотучыларга җиңеллек килде. Иманнары нык, таза-сау булган кешеләр уразага керде. Көннең озынлыгы, билгеле, сизелә. Көнозын эштә булган гаиләле кешеләргә бераз кыенрак. Ләкин күпләр бу вакытта каникулда, отпускта. "Ризван" мәчете быел да Рамазан аена ныклап әзерләнде. Узган елгы эсселектә бер кондиционер куйган идек. Ул гына аз булды. Быел тагын берне куярга булдык. Теләгән һәркем килеп, салкынча һавада вакытларын уздыра ала. Кондиционер безгә тәравих вакытларында да ярдәм итә, һәр көн мәчетебез тулы була. Соңгы дүрт-биш елда ифтарларны Рамазан аеның һәр көнендә дә үткәреп киләбез. Оештыручылар мәхәллә халкы арасыннан табыла. Мәчетебездә көн саен йөз иллеләп кеше авыз ача, - дип сөйләп китте "Ризван" мәчете имам-хатыйбы Алан хәзрәт Панарин.

Авыз ачу мәҗлесләрен оештырасың килсә, схема бик тә гади: имамнарга мөрәҗәгать итәсең, алар сиңа эшнең тәртибен, нәрсәләр таләп ителүен, азык-төлекнең ниндиләре кирәк булуын аңлатачак. 1999 елда сафка баскан мәчетнең проектында барысы да күз уңында тотылган булган икән. Казанның башка мәчетләреннән аермалы буларак, ифтарлар биредә мәчетнең подвалында уза (яңгырдан, чебен-черкидән "качу" өчен бик тә уңай).



Ашханә дә шунда. Ризыкны ташу өчен мәчетнең төп керү юлы файдаланылмый. Хуҗалык эшләре барганны мәчеткә килүчеләр сизми дә. Тәһарәтханә дә аскы катта. Мәчетнең бар җирендә дә чисталык, тәртип хөкем сөрә. "Килүчеләр бар яктан да канәгать кала, яратып китәләр. Мәхәллә халкы ишәйгәннән-ишәя, ул Горки микрорайоны чикләреннән күптән чыгып китте инде. Дачаларда, шәһәр яны авылларында яшәүчеләр - саный китсәң, шактыйга җыйнала. Шәһәр транспорты тәравих намазлары беткәнче йөрүдән туктый. Юдино, Нагорный, Азино, Усад якларыннан да киләләр безгә, машиналы кешеләр үзләре ягына кайтучыларны ала. Мультфильмда да бит "Труд объединяет" дигән лозунг бар. Әлеге мисалда исә безне Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү теләге берләштерә", - дип сөйләде Алан хәзрәт.

Пешерү-төшерү эшләрен мәчетнең үз хезмәткәрләре башкара икән. "Кызларыбыз иртәнге намазга кадәр савыт-саба юа", - ди хәзрәт.

Мәчеткә нигез салган Ризван Гаязовка моннан ике ел элек инсульт булган иде. "Шушы Х.Мәүлетов урамындагы мәчетне төзегән Ризван хәзрәтнең хәле уртача, ярыйсы. Үзенең ихтыяр көче белән ул аякка басты. Гәрчә, аңа табиблар: "Йөри алмыйсың", - дип әйткән булганнар. Аны җомга намазына алып киләбез. Ул әле дә азан әйтә, тәһлилләр чыга, Рамазан аенда тәравих зекерләрен укый", - дип белдерде А.Панарин.

Исегезгә төшерәбез: Ризван хәзрәтнең дин юлындагы эшчәнлеге күптәннән, узган гасырның 90-нчы елларыннан башлана. Хәзрәт бу мәчетне төзетүдә җаны-тәне белән катнаша. "Мәчеткә халыкның күпләп агыла башлавына да Ризван хәзрәт сәбәпче булды. Коммунизмнан арынып бетә алмаган буынны ул алып килде, - дип сөйләде мәчетнең хәзерге яшь имамнары. - Ул үзенең әхлагы, ярдәмчеллеге, тырышлыгы белән дәгъват кылды. Җомга намазларында мәчетебездә буш урыннар да булмый".

Мәчеттә ел әйләнәсе җанлылык хөкем сөрә. Быел исә кыш көннәрендә спартакиадалар үткәрергә планлаштыралар. Ислам дине белеме буенча интеллектуаль бәйге дә уздырырга ниятлиләр. Хуҗалык эшләрендә дә туктап торырга исәпләре юк. Күптән түгел генә мал чалу өчен махсус урын - Корбан сарае төзеп куйганнар. Узган уку елында гына Парин урамына Университиада авылы "төшеп утырган" иде. Студентларга мәчет кул сузымында гына - мөселман яшьләре аны озак эзләп йөрмәгән. Ливия, Йәмән студентлары "Ризван"да булырга өлгергән дә инде. "Алардан без гарәп теле буенча күнекмәләр алабыз", - ди мәчеткә йөрүчеләр. 2013 елга кадәр "Ризван"га артык зур чыгымнар тотмыйча гына ремонт ясап алырга да исәпләре бар. Тагын бер шатлыклы хәбәр: Идел буе районында тагын бер мәчет төзелеше башланып китте. Ул Р.Зорге белән Имәнлек (Дубравная) урамнары кисешкән урында булачак.

Мәчеттә булган чакта минем күңелемә шунысы да сары май булып ятты - хәзрәтләрнең барысы да халык белән татар телендә аралашырга тырыша. "Вәгазьләр дә гел ана телебездә генә үтә. Ихтыяҗ булганда кайбер мәсьәләләрне генә биш минут русча аңлатып китәбез", - ди Алан хәзрәт.

"Ризван" мәчетендә хезмәт куючы дин әһелләре Рамазан ае уңаеннан газетабыз аша үз теләкләрен җиткерүне дә үтенделәр.

- Иң беренче чиратта, безнең өстебезгә йөкләнгән фарыз гамәлне үтәүдә сабырлык, түземлелек телибез. Уразабызны Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән тотсак иде. Аллаһ боерса, үз-үзебезне кулда тотып, барчабызга да уразаларны тотып чыгу насыйп булса иде, - дип теләп калды алар.

**Нияз САБИРҖАНОВ.**

Мансур хәзрәт ҖӘЛӘЛЕТДИН:

# "РАМАЗАН АЕ КЕШЕЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ"



**Рамазан-шәриф аеның да инде яртысы үтеп бара. Республика мәчетләрендә ифтарлар үткәрү, җәмәгать белән бергәләшеп тәравих намазлары уку дәвам итә. Казан шәһәре мәчетләрендә әлеге изге ай ничек үтә, кыенлыклар бармы - боларның барысы белән дә Казан шәһәре мөхтәсибе, "Мәрҗани" мәчетенең имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдин таныштыра.**

***- Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү, Мансур хәзрәт! Үзегез имам-хатыйб булып торган "Мәрҗани" мәчетенең Рамазан аендагы эшчәнлеге белән таныштырып үтсәгез иде...***

- Бирегә мин узган гасырның 80 нче елларында килдем, "Әл-Мәрҗани" бу вакытта Казанда бердәнбер мәчет иде. Инде ул елларда ук халык ураза тота, ифтарлар үткәрелә иде. Шәһәребезнең Мирный, Дәрвишләр, Петровский кебек бистәләреннән кешеләр авыз ачарга, вәгазь тыңларга һәрвакыт мәчеткә агылды. Халыкта бер күркәм гадәт бар иде - һәр кеше үзе белән нәрсә булса да пешереп, алып килә иде. Берләре бәлеш һәм камыр ризыклары пешерсә, икенчеләре бәрәңгеләргә хәтле пешереп китерә. Пироглар булсынмы, бәлешләр булсынмы, чәйләр, шикәрләр, кайнатмалар - нәрсәләр генә юк. Үзләре ураза тотмаучы кешеләр дә ризыклар алып килгәлиләр иде. Узган гасырның 90 нчы елларында да бу матур традиция сакланды. Рамазан аеннан артып калса, алып киленгән әйберләрне аерым җыеп, картлар, балалар йортларына, ятимнәргә, мескеннәргә тарата идек. Кызганыч, нигәдер бүгенге көннәрдә бу гадәт бетте.

Шулай бергәләп матур итеп авыз ачалар, авыз ачканнан соң Коръән, аннан тәравих намазы укыла, намаздан соң дүрт автобус шәһәрнең 4 ягына халыкны тарата китә иде.

Алда әйтелгәнчә, "Мәрҗани" мәчетендә авыз ачулар элек-электән булды, башта подвалда ясый идек, кыш көннәрендә мәчетнең беренче катында була иде. Бүгенге көндә, әлбәттә, Әлхәмдүлилләһ, мөмкинлекләр үсте. Казанның 1000 еллыгына мәчет янына өч йөзгә якын кеше авыз ача алырлык чатыр куйган идек, шул вакыттан бирле ел саен чатырда ифтарлар үткәрелеп килә. Шәһәребезнең төрле почмакларыннан кешеләр килә, теләге булган һәр кеше ифтар кыла ала, берсен дә кире какканыбыз юк.

***- Дин кардәшләребез өчен Рамазан ае нинди көчкә ия?***

- Халык уразаны һәр ел көтеп ала. Рамазан аеның кешеләрне берләштерә торган ниндидер көчкә ия булуына елдан-ел инанасың. Бер уйласаң, намазы да, зәкяте дә, хаҗы да фарыз бит, тик боларга игътибар азрак, ә менә Рамазан аена халыкта аерым бер караш. Үзләре ураза тотмасалар да, ураза тотучыларга бик ихтирамлы карыйлар, үзара яхшырак мөгаләмәдә булырга, уразалы кешеләргә булышырга тырышалар.

***- Ифтарларны үткәрергә читтән ярдәм күрсәтеләме?***

- Әйтеп үткәнебезчә, элегрәк ифтар мәҗлесләренә кешеләр үзләре белән ризыклар алып киләләр иде. Соңыннан, кайбер сәбәпләр аркасында ураза тота алмаучы кешеләр, ризык пешереп, авыз ачтырыгыз әле дип, мөмкинлекләреннән чыгып, аз-азлап акча бирә башладылар. Иганәчеләр дә барлыкка килде, бүгенге көндә үземнең попечительләр советым бар. Ел саен дусларым бу вакытны көтеп ала. Гадәттәгечә, үзара сөйләшеп, аерым берәр көнне авыз ачтыра. Шул рәвешле ифтар үткәрүнең бу ягы матур бер гадәткә әверелде.

***- Мансур хәзрәт, сез бит әле Казан имам-мөхтәсибе дә. Казанның башка мәчетләрендә Рамазан ае ничек үтә?***

- Мәркәзебездә алтмышка якын мәчет бар, бүгенге көндә аларның яртысында диярлек ифтарлар үткәрелә. Кайсылары көн саен, кайсылары айның аерым бер көннәрендә үткәрә. Мәсәлән, узган елларны "Рамазан", "Ризван" мәчетләрендә алдан килешенеп, фәлән кеше - шуны, фәлән кеше - шуны, дип бүлешеп, кемнең нәрсәгә мөмкинлеге бар, шуны эшләп, җыелышып, бергәләп авыз ачтыралар иде. "Казан нуры", "Нурислам", "Болгар", "Ризван", "Рамазан", "Сөләйман" мәчетләре ифтар мәҗлесләрен шулай ук, даими үткәреп киләләр.

***- Сезнең инициатива белән беренче тапкыр республикада Ураза бәйрәме үткәрелгән иде. Быел бәйрәм Республика көненә туры килә. 30 август көнне гает намазы укудан тыш Ураза бәйрәме үткәреләчәкме?***

- Әлбәттә, үткәрәчәкбез, гает көннәрендә 3 көн рәттән бәйрәм итәргә ниятебез бар. Мөнәҗәтләр, бәетләр белән үзебезнең ансамблебез дә катнашыр дип көтелә.

***- Рамазан-шәриф аенда газета укучы дин кардәшләребезгә сездән теләкләр...***

- Шундый эссе озын көннәрдә ураза тотучыларга сабырлык телим, кылган изге гамәл-гыйбадәтләрегезнең әҗер-савабын күрергә насыйп булсын! Уразаларыбызны Аллаһы ризалыгы өчен тотып, игелекле гамәлләр кылып үткәрергә, начар гадәтләрдән арынырга язсын! Аллаһы Тәгалә барыбызга да ярдәм бирсен! Илебезгә, динебезгә тынычлык һәм иминлек бирсен, киләсе уразаларыбызны да шулай бергә-бергә үткәрергә насыйп итсен. Ураза тотучыларыбыз да, мәчетләрбез дә арта, Аллаһы Тәгаләнең дине барыбызны да берләштерә. Дин тотмаучы кешеләргә дә әлеге Рамазан аенда начар гадәтләрдән арынырга, дингә һәм иманга килергә Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсә иде!

**Алинә БИКМУЛЛИНА**

*Лена КОСТЮХИНА:*

# "БИШ ЙӨЗ МЕҢЛЕК ШӘҺӘР ӨЧЕН ИКЕ МӘЧЕТ ҺӘМ ЗУР МӨСЕЛМАН МӘКТӘБЕН БУЛДЫРУ БИК ЗУР УҢЫШ ДИП САНЫЙМ"





**Менә инде ике семестр буе Америка Кушма Штатларындагы кечкенә генә бер колледжда укыйм. Бирегә зур конкурста катнашып, алмашыну программасы буенча студент булып килдем, шуңа күрә уку йортын да үзебез сайламадык, харәҗәтче оешмабыз сигезебезне лютеран колледжга җибәрде.**

Бергә килгән дусларымның берсе - рәсми рәвештә мөселман иле булып танылган Таҗикстаннан, өчесе - шулай ук мөселманнар күпләп яши торган Үзбәкстан белән Казахстаннан. Әмма монда лютеран колледжта укыган кеше лютеран булырга тиеш дигән ышаныч инде күптән юкка чыккан, исеме дә күбрәк тарихына һәм спонсорларына бәйле, ягъни колледжга акчалата булышкан оешмаларның күбесе - лютеран чиркәүләр.

Уку йортыбыз урнашкан шәһәр дә артык зур түгел һәм Канзасның нәкъ уртасында. Зур шәһәрләрдә башкачарак, анда төрле милләтләр, төрле дин кешеләре яши, ә безнең шәһәрдәге халыкның барысы да диярлек нинди дә булса христиан чиркәүгә карый. Шулай да башка дин вәкилләренә дә кызыксыну бар, алар турында күбрәк белергә, үзләре турында сөйләргә тырышалар, фикер каршылыклары бары тик дәресләрдә үткәрелгән бәхәсләр вакытында гына килеп чыга, һәм күп очракта объектив фактларга нигезләнгән. Монда гомеремдә беренче тапкыр күргән кешенең синең белән исәнләшүенә беркем дә аптырамый, кичке алтыдан соң урамда күренгән кешеләр бик сирәк, кибетләрнең күбесе дә шул вакытта ябыла. Безнең Линдсборгта бигрәк тә.

Ураза вакытында без бер яһүд укытучыбыз белән бергә күрше зур шәһәргә бардык, дөресрәге, ул үз эшләре белән кәнәсәгә барган иде, ә без аңа ияреп Уичитаның мөселман үзәгенә. Юл дәвамында яһүд дине белән ислам дине арасындагы охшашлыклар турында фикер алыштык. Яһүдләрнең сәламләүләре безнең "Әссәламегаләйкүм"гә бик якын икән! Үзәккә барып җитүгә үк күзгә чалынган беренче әйбер - монда мәчетләрне бездәге кебек бөек сәнгать әсәрләре итеп төземиләр, бер гөмбәзле гади генә бина, шуның эчендә мәчет үзе һәм балалар өчен мәктәп тә урнашкан, иң кечкенәләрдән башлап югары сыйныфларга хәтле. Канзаста, гомумән, мөселманнар әллә ни күп түгел дип уйлыйм, алар күбрәк Нью-Йорк, Лос-Анджелес, Бостон кебек зур шәһәрләрдә яши, шуңа күрә биш йөз меңлек шәһәр өчен ике мәчет һәм зур мөселман мәктәбен булдыру үзенә күрә бер уңыш дип саныйм.

Җыелган халыкның саны биш йөзгә якын булгандыр, кеп-кечкенә балалардан башлап ак сакаллы бабайларга хәтле, әле үзләре каян гына килмәгәннәр АКШка! Кемдер Азия илләреннән, кемдер Европадан, Төньяк Америкадан, кемдер балачагыннан бирле монда яшәгән, хәтта Кубада туган бер ханым белән дә таныштык.




Гомумән, мондагы мөселман оешмаларының тормышы бик кызык, ураза вакытында һәр көнне ниндидер аерым илнең милли ашамлыклары белән авыз ачалар, бу ашамлыкларны әзерләү өчен шул илнең вәкилләре җаваплы. Без килгән көн Һиндстан көне иде. Яңа кешеләрне бик тә кунакчыл кабул итәләр, әмма бу мондагы дини оешмаларның уртак үзенчәлеге дип уйлыйм, чөнки һәрберсе үзенең вәкилләре санын үстерергә тырыша, хәтта радиодан чиркәүләрнең рекламаларын да ишеткәләгәнем булды.

Тик демократия илендә дә "чит" диннәрне күзәтеп торырга омтылган кешеләр бар. Рәхмәтләребезне әйтеп кире юлга чыккач, безне алып килгән укытучыбыз безгә кайсыдыр зур шәһәрдә төзелә торган мәчет турында сөйләде, шуңа акча биргән бөтен кешеләрнең исемнәрен язып барырга җыеналар икән, ә аларның яһүди оешмалары моңа каршы, чөнки мөселманнарны язып чыккач, яһүдләрне тикшерә башлаячаклар дигән фикердә. Нәрсә белән беткәндер бу вакыйга, әйтә алмыйм, тик бу илдә һәр милләтнең, һәр диннең вәкилләре булганы, чынлап та, дөрес.



**Лена КОСТЮХИНА,**
**АКШ, Канзас штаты**

# Хәзерге җәмгыятьтә диндарлар

**Күп вакыт кешеләр үз алларына түбәндәге сорауны куялар: дингә ышанырга безне нәрсә этәрә? Минем үземә дә кайвакыт әйләнә-тирәдәгеләрдән шуны ишетергә туры килә: ни өчен матур, укымышлы кызлар яулык ябына, үзләренең сылу гәүдәләрен чүпрәккә төреп бетерә? Ни өчен эшлекле бизнесмен, бар эшен ташлап, биш вакыт намазга бүленә? Ни өчен кешеләр эссе җәй көнендә үзләрен утыз көнлек уразага багышлый?**



Борынгы гасырлардан бирле дин җәмгыятьнең аерылгысыз бер өлеше булган, һәм ул һәрвакыт безнең тормышыбызда булачак. Совет власте елларында үткәрелгән динсезлек тә халыкны аннан аера алмады. Ышану безнең йөрәкләрдә яши һәм яшәячәк. Бу ник алай? Беренчедән, дин кешегә тормышының иң мөһим сорауларына җавап табарга ярдәм итә. Кем мин? Ни өчен мин бу дөньяга килдем? Мин кая китәчәкмен? Минем тормышымның мәгънәсе нәрсәдә?

Ышану аша кеше Аллаһы Тәгаләгә якыная. Хәзерге җәмгыятьтә дингә китерүче башка сәбәпләр дә бар. Без мәгълүмати технологияләр чорында яшибез. Бу чор безнең тормышыбызда уңай шартларны күп тудыра. Шулай да кеше бүгенге көндә кредит колына, карьера һәм тотрыксыз үзгәрүчән технологияләр колына әйләнүен дәвам итә. Кеше, чираттагы кредитын түләү өчен, үзенең эчен тышка әйләндерә. Фирмалар үзара рәхимсез көрәш алып бара, ә андагы хезмәткәрләр шулай ук үзара проектлар, хезмәт урыннары һәм эш юнәлеше буенча көндәшлек күрсәтә. Шуның нәтиҗәсендә кеше гел экстрим шартларда яши. Аның якыннары янәшәсендә булырга, гаиләсен һәм туганнарын кайгыртырга вакыты калмый. Хәзерге заман кешесенең, кулына китап алып, сәнгать белән хозурланырга, шулай ук, бер минутка туктап, үз тормышының мәгънәсен аңларга һәм яшәешенең асылын күрергә теләге калмый. Чираттагы социаль казанышлары артыннан чабып, тормышын бер юнәлешкә сала ул. Күпләр моннан арый башлый. Артык мәгълүматтан алар инде туйган. Мәгълүматлар шулкадәр күп ки, кеше аңларга һәм үзләштерергә өлгерә дә алмый. Windows системасының яңа версиясе чыгу безгә яңа мөмкинлекләр бирүгә дә карамастан, ул шатлык уятмый. Кешеләр бу яңалыкны күңелсезләнеп каршы ала. Ник дигәндә, бөтен булган мәгълүматны яңадан компьютерга урнаштырырга һәм аның бөтен программасын алыштырырга кирәк булачак. Кешеләр еш кына чираттагы кәрәзле телефоннары белән саубуллаша. Яңасын алгач, яңадан-яңа функцияләр, яңа дизайн һәм яңа опцияләр асылын аңларга кирәк була. Кеше болардан ара. Шундыйлар арасыннан: "Җитә! Минем яшисем килә! Мин бу ярышны кире кагам! Мин якыннарым өчен вакыт табарга телим!" - диючеләр була. Күпләр бу ярыштан чыгу юлын дингә мөрәҗәгать итеп таба. Нәкъ менә дин, бүгенге логиканы аңларга, "җитте"нең асылына төшенергә ярдәм итә. Үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүгә юнәлтелгән җәмгыятьнең төп кыйммәтләре перспективасызлыкка һәм һәлакәткә китерүен бүгенге көндә гади халык та, дәүләт эшлеклеләре дә аңлый башлады.

Безнең тотнаксыз булуыбыз, бер кирәксезгә икенче телефонлы булырга, кайвакыт икенче, өченче машиналарны алырга этәрә. Болай эшләү, безнең җиребезнең киләчәгенә киртә тудыра. Без планетабызның барлык ресурсларын үзебезгә суырабыз. Киләчәк буынга бары тик куркынычлык кына калдырабыз. Бүгенге нормаль булмаган җәмгыятьтә шундый фикер үсә: куллану - ул байлык түгел, бу - безнең җиребезнең тормышына тәэсир итүче зыян гына. Беренче булып, кемнәр моны аңлаган? Алар диндар кешеләр булган. Алар куллану уеннарында уйнамый. Үзләренең кыйммәтләрен аңлап, буыннардан килгән кагыйдәләр буенча, дингә таянып яши. Шуңа күрә дини консерватизм барлыкка килгән. Без аны шәһәр урамнарында күрә алабыз. Кызларның ябык киемнәр киюе, намазлык һ.б. - бу шәхси сайлау түгел, ә җәмгыятьнең һәр очракка үз җавабы. Моңа җавапны без һәрберебез теге яки бу формада табарга тиешбез.

**Гүзәл ГАБДРАХМАНОВА.**
**(Рөстәм Батыр вәгазе файдаланылды)**

---

## Җиң сызганып – тулы көчкә!

***Быелгы җәй күп кенә мәчет-мәхәлләләрдә кызу урак өстен хәтерләтә. Җәй башлануга, балалар өчен аерым сабаклар, мөселман лагерьлары да оештырырга өлгермисең, инде Рамазан шәриф аена багышланган мәҗлесләр башланып китә. Шулай да республикабызның мөхтәсибәтләре сынатмый.***

Бу яктан Тукай районын күп кенә мөхтәсибәтләргә үрнәк итеп куярлык. Шушы ярты ел эчендә генә дә мөхтәсибәттә биш йөзгә якын чара үткәрелгән, Калмия, Боерган, Күзкәй, Калмаш, Яңа Мусабай мәхәлләләрендә халык белән очрашулар булган, вәгазьләр сөйләнелгән.

"Июнь-июль айларында мәктәп яшендәге балалар өчен Теләнче Тамак, Иске Дөреш, Бикләң, Калмия, Боерган, Күзкәй, Яңа поселогы, Калмаш, Мусабай, Ташкичү, Сәмәкәй, Иске Абдул, Кече Шилнә, Новотроицк, Иштирәк мәктәпләрендә махсус җәйге лагерьлар оештырылды. Әлеге лагерьларда ислам әхлагы, дини нигез, гарәп теле дәресләреннән сабак бирелде. Ата-аналар да лагерьлар эшеннән бик канәгать калды, Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсә, киләсе елларда мондый төрдәге мөселман лагерьларын арттыру нияте бар", - дип үзенең теләген җиткерде Тукай районы мөхтәсибе урынбасары, дәгъват бүлеге җитәкчесе Рәфикъ хәзрәт Гыйльфанов.

Шунысы да күркәм: Тукай районының "Якты юл" газетасында мөхтәсибәткә аерым бер кушымта каралган, дин әһелләре район халкын очрашуларда гына түгел, атнасына ике тапкыр чыга торган газета битләре аша да ислам әхлагы, дини бәйрәмнәр, шәригать кануннары белән һәрдаим таныштырып баралар.

**musulman.su сайтыннан алынды**

---

# "Ул бер генә ай түгел, күбрәк булсын иде дим"

**ИЗГЕ Рамазан ае безне хәрәмнән, ялганнан, явызлыклар кылудан тыелырга, Аллаһы Тәгаләгә якынрак торырга, изгелекләр эшләргә, бер-беребезгә шәфкатьле булырга чакыра. Ураза тотканнан соң күңел пакьләнеп, сафланып калса, организм өчен дә файдасы зур аның.**

**Тән җиңеләеп киткәндәй була. Әмма ураза тоту бар мөселманның да хәленнән килми. Ул зур ихтыяр көче сорый. Ә сез ураза тотасызмы?**

**Римма ИБРАҺИМОВА, Татарстанның халык артисткасы, җырчы:**

- Даими гастрольләрдә йөргәч, уразаны тота алганым юк. Анда режим бозыла, юлда йөрүе дә җиңел түгел. Әмма бу аклану гына булыр. Хәзер яшь барган саен, сәламәтлек тә үзен сиздерми калмый. Шулай да Аллаһы Тәгаләне гел күңелемдә йөртәм, авыр хәлдә калганнарга мөмкин кадәр сәдакасын бирергә тырышам.

**Салават МИҢНЕХАНОВ, җырчы, Азнакай районы хакимиятенең мәдәният бүлеге башлыгы:**

- Ураза ае башлануны ел буе түземсезлек белән көтәм. Аның бер көнен дә калдырмаска тырышам. "Эсседә ничек тотасың?" - дип гаҗәпләнеп сорый кайбер танышларым. Аның авырлыгы юк, бары тик ихтыяр көче булу кирәк. Ураза тотарга теләге бар кешеләргә Аллаһы Тәгалә ярдәмен бирә ул. Ашыйсы да, эчәсе дә килми. Изге ай үтеп киткәч, күңел тынычланып калгандай була, ниндидер рәхәтлек сизелә. Ул бер генә ай түгел, күбрәк булсын иде дим, аның тиз үтеп китүен теләмим.

**Рәмзилә ХӨРМӘТОВА, "Татарстан хәбәрләре" хәбәрчесе ("ТНВ"):**

– Әби белән үстем. Шуңа күрә кечкенәдән сәхәргә торып, аның белән авыз ача идем. Хәзер дә, Аллага шөкер, уразаны калдырганым юк.

Аллаһы Тәгалә бәндәләренә бер ай буе гөнаһлардан арыну, җәннәткә якынаю мөмкинлеге бирә. Аннан файдаланырга кирәк. Соңгы елларда ураза көннәре озын вакытка туры килә, әмма бу сынауны да без үтәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә Исламда кешенең тормышына, сәламәтлегенә зыян китерә торган нәрсәләрне булдырмаган. Моны "Ашамыйча йөреп, сәламәтлегеңә зыян китерәсең", - диючеләргә җавап буларак әйтәм. Ходай җиңеллеген бирә ул. Сүз дә юк, эшләгән вакытта көнозын су эчмичә, һаман юлда йөрү авыррак. Аеруча беренче көнне. Әмма шул рәвешле үзеңдә түземлек, сабырлык кебек сыйфатларны тәрбиялисең, мохтаҗлыкта яшәүчеләрнең хәлен аңларга өйрәнәсең.

**Илнар ХӨСНУЛЛИН, "Ватаным Татарстан" газетасы журналисты:**

- Бу - һәркемнең шәхси эше. "Мин ураза тотам", дип кычкырып йөрисем килми. Хәлемнән килгән кадәр тотам. Изгелек кылу, сәдакага килгәндә, мохтаҗ кешеләргә болай да булышырга тырышам. Моның өчен Рамазан аен көтеп ятарга кирәкми.

**Әлфия КАМАЛИЕВА, теш табибы:**

- Кечкенәдән янәшәбездә әби дә булганга, уразаның нинди зур, изге ай икәнен белеп, догаларын өйрәнеп үстем. Ул иртән сәхәргә торганда, мин дә уянам, барысын да күзәтә идем. Үзем бик теләсәм дә, тота алмыйм. Аллаһы Тәгалә кичерер, дип уйлыйм, чөнки соңгы елларда ашказаны җәрәхәтеннән интегәм, операция дә кичердем. Дарулар да еш эчәргә туры килә. Ә болай сәдаканы гел бирәм, ел саен аш үткәрергә тырышам.

**Морат СИРАҖИН, Югары Ослан районы Шеланга авылы, фермер:**

- Тәүлегенә 14-16 сәгать эшлим. Кешеләр, намаз укып, ураза тотып, үзләре өчен теге дөньяда җәннәт әзерләргә тырышса, мин аны исән вакытта булдырырга телим. Ураза тотмыйм, мәчетләргә дә йөрмим. Андагы имам-хәзрәтләргә сәдака бирмим. Мине гафу итсеннәр, бөтенесен бер калыпка салып әйтүем түгел. Әмма арада халык җилкәсендә утырган, әллә ни эш башкармаган дин әһелләре дә бар. Аларга хәер биргәнче, күз алдындагы авыр хәллеләргә булышам.

**Гөлнара ТИМЕРҖАНОВА, җырчы:**

- Уразаны калдырмый тотарга тырышам. Бу изге айга алдан ук әзерлек эшләрен башладым. Организмны чистарттым, ашауны кыстым. Хәер, әзерлек эше алып бармаган очракта да, әллә ни кыенлыгы булмас иде. Аллаһы Тәгалә Аның ризалыгы өчен тотканнарга бик теләп ярдәм кулын суза. Ураза тота башлагач, үземдә үзгәрешләр сизәм. Күңелем тынычлана, яшәү дә матуррак тоела. Тормышта барына канәгать булырга, артыгын кумаска, Аллага шөкер, дип торырга кирәк. Бу ике көнлек дөньяда бер-беребезнең, якыннарыбызның кадерен белеп калыйк, изгелекләрне күбрәк кылыйк. Ураза шушы гамәлләргә чакыра.

**Лилия ЙОСЫПОВА.**
**"Ирек мәйданы" газетасыннан**



***Идел буенда Ислам дине тыныч юл белән тарала. Гарәп миссионерлары эшчәнлеге, шулай ук Шәрык илләре, аерым алганда, Иран һәм Урта Азия белән күпьеллык сәүдә-икътисади һәм мәдәни багланышлар бу төбәктә Ислам дине көчәюгә зур этәргеч ясый.***









# ИДЕЛ БУЕНДАГЫ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ ҮСЕШЕН ӨЙРӘНҮ

Ислам дине кабул ителү Идел буе Болгарстанының идеологик һәм мәдәни тормышында гаять мөһим үзгәрешләргә китерә. Бигрәк тә татар мәдәнияте үсешенә фәлсәфи-эстетик карашлар үтеп керә.

Урта Идел буендагы мөселман сәнгате, 922 елдан соң, җирле халыклар мәдәнияте белән бергә рухи яктан үзара бәйләнештә үсә башлый.

Башта шунысын искәртик: Урта Идел төбәгендәге Ислам дине мәсьәләсе моңарчы тиешенчә өйрәнелмәгән иде. Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, моның сәбәбе - Идел буен классик Ислам җире дип санамауда.

Минемчә, "Болгар тарихы" китабын язган, Болгар иленең тарих мәктәбе вәкиле Якуб ибне Ногманны Идел буе Болгарстаны тарихын өйрәнүгә нигез салучы дип санарга мөмкин. Әлбәттә, болгарлар үз тарихларына кагылышлы төрле риваять, җыр, хикәятләрне буыннан буынга тапшыра килгәннәр.

Болгар чорына караган истәлекләр белән кызыксыну XVIII йөз башында башлана. 1712 елда дьяк (борынгы Россиядә берәр дәүләт учреждениесенең эшләрен алып баручы) А.Михайлов борынгы Болгар шәһәрлеген тасвирлап яза, андагы күп кенә бина һәм корылманы күрсәтә. 1722 елда Петр I, киләчәктә биредәге истәлекле урыннарны саклау чаралары күрү максатын күздә тотып, Болгар җире хәрабәләре белән танышып китә.



В.Татищев исә үзенең "История Российская с древнейших времен" (1768) дигән хезмәтендә, борынгы рус елъязмаларына һәм башка чыганакларга нигезләнеп, монгол чорына кадәр яшәгән болгарларның тормышын һәм тарихи вакыйгаларны тасвирлый. Бу чорда инде күптөрле тикшеренүләрне колачлаган экспедицияләр дә шактый еш уздырыла. Н.Рычков, П.Паллас, И.Лепехин болгар чоры истәлекләрен иң башлап өйрәнүчеләр була.

1804 елда Казан университеты ачылгач, Идел буе Болгар дәүләте тарихын, археологиясен, нумизматикасын өйрәнү сизелерлек активлаша. Әхмәд ибне Фадланның мәгълүм сәяхәтнамә язмаларын иң беренче булып дөньяга чыгарган Х.Френны хаклы рәвештә Шәрык нумизматикасына нигез салучы дип йөртәләр. Ул үз хезмәтләрендә Болгар чорына караган кайбер археологик табылдыкларны һәм борынгы риваятьләрне тасвирлап язган.

XIX гасырга караган колачлы археологик тикшеренүләр И.Березин, К.Евлентьев, К.Невоструев, А.Второв, А.Артемьев, Н.Вячеслав хезмәтләрендә чагылыш тапкан.

1878 елда Казан Император университеты каршында оештырылган Археология, этнография һәм тарих җәмгыяте Болгар чоры историографиясен өйрәнүгә зур этәргеч ясый. Әлеге чор А.Лихачев, М.Худяков, В.Смолин, В.Казаринов, Н.Смирнов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Г.Әхмәрев, З.Вәлиди кебек күренекле галимнәр эшчәнлеге белән нык бәйле. Бу җәһәттән, Ш.Мәрҗанинең - "Мөстәфадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар", Р.Фәхреддиннең - "Болгар һәм Казан төрекләре", Г.Әхмәревның - "Болгар тарихы", З.Вәлидинең "Төрки-татарларның кыскача тарихы" китаплары аерым игътибарга лаек.

Болгар дәүләте историографиясе үсешендә профессор В.Смолинның "К вопросу о происхождении народности камско-волжских булгар" китабы (Казан, 1921) мөһим урын тота. Ул әлеге китабында, беренче тапкыр буларак, Идел буе Болгарстаны тарихын фәнни яктан чорларга, аерым алганда, башлангыч Болгар чорына (VII-IX гасырлар), монгол чорына кадәр (X-XIII гасыр башы), Алтын Урда чорына (1236-XV гасыр) бүлеп карарга тәкъдим итә.

XX гасыр башы Болгар чорына караган тарихи истәлекләрне өйрәнү максатында төрле экспедицияләр оештырылу белән үзенчәлекле. Идел буе Болгарстаны историографиясен өйрәнүгә археолог А.Смирнов зур өлеш кертә. Аның күпкырлы эшчәнлеге Идел буе Болгарстанының иң зур истәлеге - Сувар шәһәрлеген өйрәнүдән башлана. Нәкъ менә биредә беренче тапкыр Болгар дәүләте шәһәрләре казылмаларын өйрәнүнең фәнни методикасы эшләнә. Сувар һәм Болгарда үткәргән тикшеренү нәтиҗәләре галимнең 1944 елда яклаган докторлык диссертациясенә һәм 1951 елда басылып чыккан "Волжские булгары" монографиясенә нигез була.

Гомумән, XX гасыр Идел буе Болгарстаны турындагы тарихи белемнәр үсешендә актив археологик тикшеренүләр чоры буларак тәгаенләнә. Т.Хлебникова, А.Ефимова, Г.Федоров-Давыдов, А.Халиков, В.Генинг, Р.Фәхретдинов һ.б. археологлар, Идел буе Болгарстаны тарихын тулыландырып, Болгар дәүләте шәһәрләренең яңа һәйкәл-истәлекләрен җентекләп өйрәнде. Мәсәлән, Т.Хлебникова, И.Васильева, Н.Кокорина, А.Кочкина - үз хезмәтләрендә болгарларда керамик савыт-саба ясау, Ю.Семыкин - металларның төзелешен һәм физик үзлекләрен өйрәнү, С.Вәлиуллина пыяла эшләнмәләр мәсьәләләрен яктырта. Н.Калининның "Булгарское искусство в металле" хезмәтендә татар халкының зәркән сәнгате җентекләп өйрәнелгән.





Шулай да сәнгать белгече Фоат Вәлиевне X-XIII гасырлардагы болгар сәнгате турында иң башлап фундаменталь хезмәтләр язган галим дип санарга бурычлыбыз. Аның 1969-1983 елларда дөнья күргән "Орнамент казанских татар", "Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья" дигән китапларында монгол чорына кадәрге һәм монгол чорындагы рухи мирас ныклап тикшерелә.

Е.Халикова хезмәтләрендә исә монгол чорына кадәрге Идел Болгарстанында Ислам диненең тарала башлавы һәм таралу дәрәҗәсе беренче мәртәбә фәнни нигездә өйрәнелә.

Г.Дәүләтшин үзенең "Волжская Булгария: духовная культура" дигән хезмәтендә Ислам дине таралу белән рухи мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә булган үзгәрешләргә һәм яңалыкларга туктала. Ул гарәп язуы таралу нәтиҗәсендә Идел Болгарстанына язма әдәбият үтеп керүен ассызыклый.

XIX гасырның 70 нче елларында Казан университеты профессоры С.Шпилевский, ә соңрак беренче татар тарихчысы Ш.Мәрҗани Болгарстанның монгол явына дучар булган чоры һәм Алтын Урда тарихын өйрәнү кирәклеген күтәреп чыга. Аерым алганда, Ш.Мәрҗанинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар" (Казан, 1897; 1989) һәм С.Шпилевскийның "Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии" (Казан, 1877) дигән китапларында Алтын Урда чорындагы болгар-татар калаларына характеристика һәм аларга кагылышлы риваятьләр бирелгән.

XX гасыр башында Болгар һәм Алтын Урда тарихы күренекле татар тарихчылары Г.Әхмәрев ("Болгар тарихы", 1909) һәм Г.Гобәйдуллин ("Татар тарихы", 1922; "Тарихи сәхифәләр ачылганда", 1989) хезмәтләрендә дә күтәрелә. Әмма аларда археология, нумизматика, эпиграфия мәсьәләләре тиешенчә яктыртылмый әле.

Соңрак А.Смирнов, Н.Калинин, Һ.Йосыпов, Ф.Хәкимҗанов хезмәтләрендә Идел Болгарстанының археологик, эпиграфик һәйкәлләре хакында байтак кызыклы мәгълүматлар бәян ителә.

Татар халкының Алтын Урда чорына караган этник тарихы Б.Греков һәм А.Якубовскийның - "Золотая Орда и ее падение" (М., 1950), А.Смирновның - "Волжские булгары" (М., 1951), М.Сәфәргалиевнең "Распад Золотой Орды" (Саранск, 1960), М.Усмановның "Жалованные акты Джучиева улуса XIV-XV веках" дигән монографияләрендә төрле яклап яктыртыла. Әмма Идел Болгарстанының Алтын Урда чоры сәнгатенә генә багышланган әдәбият бик аз. Бу юнәлештә С.Червоннаяның "Искусство Татарии" (М., 1987), Ф.Вәлиевнең "Народное изобразительное искусство" (М., 1967), Г.Вәлиева-Сөләймановaның "Мусульманское искусство татар Среднего Поволжья: истоки и развитие" (Казань, 2002) китаплары тәүге карлыгачлар. Аларда Болгар чоры сәнгатенә гомуми күзәтү бирелә, аның үсеш этаплары, үзенчәлекләре күрсәтелә.

С.Айдаров - "Идел Болгарстанының монгол чорына кадәрге архитектура һәйкәлләре, аларның сакланышы, борынгы болгар төзелешенең гомуми принциплары", Д.Вәлиева "Идел Болгарстанының монгол чорына кадәрге сәнгате" дигән темаларга кандидатлык диссертацияләре яклады. 1990 елда С.Айдаров, Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы чоры архитектурасы истәлекләрен өйрәнеп, "Монументальные каменные сооружения Волжской Булгарии и Казанского ханства (опыт реконструкции и генетико-стилистические особенности)" дигән темага докторлык диссертациясе яклады.

Соңгы елларда Татарстанда милли мәдәният һәм тарихның барлыкка килү проблемаларын, аның чыганакларын өйрәнү омтылышының арта баруы сәбәпле, болгар чоры һәм Алтын Урда тарихына һәм мәдәниятенә багышланган яңа китаплар дөнья күрде. Бу җәһәттән, Р.Фәхретдиновның "Татары и Золотая Орда" (1993), А.Халиковның "Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария" (1994) китапларын, "История Золотой Орды" (1993) җыентыгын аерып күрсәтү кирәк.

**Гөлнара НИЗАМЕТДИНОВА,**
**ТФАның Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты**

# Мөхтәрәм Фаяз Шәриф улы Хуҗин!

***Сезне ихлас күңелдән Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм редакция коллективы исеменнән 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйбыз. Аллаһы Тәгалә Сезгә озын гомер, күңел тынычлыгы, саулык-сәламәтлек насыйп итсен.***



Сез республикабызда гына түгел, Россиядә, чит илләрдә дә яхшы билгеле шәхес. Хезмәтләрегезнең нәтиҗәсе фәнни мәкаләләр, китап-монографияләр, төрле конференцияләрдә, конгрессларда ясалган чыгышлар белән генә төгәлләнмәде: Биләр шәһәрлеге дәүләт карамагындагы музей-тыюлык итеп расланды, Казанның һәм Алабуганың 1000 еллык юбилейлары билгеләп үтелде.

Аллаһы җәнабел Хак Сезгә киләчәктә дә кодрәт-куәт, камил акыл, йомшак фигыль, тулы иман насыйп әйләсен. Хәләл җефетегез Гөлнур ханым белән бергә, балаларыгыз, оныкларыгызның шатлык-куанычларын күреп, аларның рәхим-шәфкатен тоеп яшәргә язсын. Ходай Тәгалә Сезне сәламәтлектән һичкайчан аермасын. Сезгә бәйле рәвештә илләребезгә, көннәребезгә, газиз Татарстаныбызга, барча галәм киңлекләренә иминлекләр юлласын!

Ватаныбыз, милләтебез өчен яхшылыклар, изгелекләр кылып күп еллар дәвамында хезмәт итүегезне телибез.

# МИЛЛӘТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ӨЧЕН ДИНИ НЫКЛЫК КИРӘК!

**"Мөселман динен тотучылар саны хәзер бер миллиардтан артып китте. Бу исә – дөнья халкының 20 проценттан артыгы. 28 илнең рәсми дине – ислам. Соңгы вакытта мөселман динен тотучыларың саны артканнан-арта бара. Ислам дине хәзерге вакытта таралган диннәр арасында икенче урында тора".**

Бер көнне радиодан шушындый сүзләр ишетергә туры килде миңа. Уйга калдым: ни өчен ислам динен тоту шулкадәр актуаль? Ислам дине тоту нәрсәне аңлата? Чын мөселман дип кемгә әйтәләр? Һәм, гомумән, нәрсә соң ул дин?

... Казан. Кояш кыздыра. Урам буйлап атлыйм. Шәһәр гөжли. Кайсы эшкә, кайсы мәктәпкә, кайсы университетка ашыга. Шәһәрдә урнашкан югары уку йортларының берсенә якынлашам. Почмакта өч студент кыз баскан. Матур гына киенгәннәр, үзләре ягымлы да кебек тоела. Бу кызларга юлны сорап мөрәҗәгать иттем.

- У вас татарский акцент, татарка, что ли? - ди кызларның берсе.

- Әйе, - дим.

Ягымлы гына елмаеп, миңа барысын да аңлатып бирде. Шул арада кесәсеннән нидер чыгарып, тәмәке көйрәтергә тотынды.

- Тартасызмы? - дип, миңа таба кулын сузды.

Дусларына да тәкъдим итәргә онытмады. Икенчеләре дә тәкъдимне кире какмадылар, карышып тормадылар, киресенчә, бик теләп кабул иттеләр.

Кызарындым-бүртендем, берни дә әйтә алмадым. Борылдым да, тизрәк бу яктан китү юлын карадым. Соңрак, рәхмәт әйтергә дә онытканлыгым искә төште.

Алга таба киттем. Тагын бер төркем студент баскан. Егетләре дә, кызлары да татар-рус сүзләрен бутап сөйли, өч сүзнең берендә - сүгенү сүзе. Кулларында - сыра. Әллә нишләп киттем. Бу бит татар халкы! Шәт, бу егет- кызлар, әбибабайларына авылга кунакка кайткач, аларның намаз укып, динне бозмыйча яшәүләрен күреп, үзләренә дә шундый юл сайлаячаклары турында, һичшиксез, уйланганнары булгандыр. Ә хәзер? Ә хәзер ни булды бу яшьләр белән?! Бу хәлгә кем гаепле? Яшьләрме? Аларның ата-аналарымы? Әллә җәмгыятьме? Әлбәттә, монда, һичшиксез, җәмгыятьнең дә гаебе бардыр. Вакытында тиешле чаралар һәм кануннар кабул ителмәде, спиртлы эчемлекләр эчү һәм тәмәке ише нәрсәләрне тарту тыелмады. Ләкин, минемчә, иң төп гаеп, әлбәттә, гаиләдә. Бүгенге заманда күп кенә яшь гаиләләр башка чыгуны хуп күрә, шуңа да аларның оялары буш. Балаларга игътибар җитми һәм алар үрнәкне үзләренең яшьтәшләреннән ала.

Ислам дине өйрәткәнчә, кеше саф мөселман булып - югары әхлакка, олы мәрхәмәткә ия булып дөньяга туа. Саф күңелле, фәрештәдәй бала үсә... Һәм тирәягындагы җәмгыять тормышының яхшы һәм бозык якларын үзенә сеңдерә башлый. Яшүсмерләрне аеруча ассызыклап үтәсем килә. Төрле микротөркемнәр барлыкка килә. "Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың", диләр. Яшүсмерләр, бер-берсеннән үрнәк алып, яманмы ул, яхшымы, барыбер, текә булып күренү өчен, яшьтәшләреннән артка калмаска тырыша.

"Оясында ни күрсә, очканында шул булыр", дигән мәкаль бар татар халкында. Кече яшьтән балага яхшы эшнең - савап, яман эшнең гөнаһ булуын аңлатырга кирәк. Моны мәгърифәтчебез Р.Фәхреддин хезмәтләренә таянып алып барсаң, үтемле була. Риза Фәхреддин бар гомерен яхшылык, белем, мәгърифәт, дин өчен көрәшкә багышлый. Мәгърифәтче-галим: "Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас", - дип яза. Шуңа күрә балаларны кечкенә яшьтән үк тиешенчә тәрбияләргә кирәк.

Хатын-кызлар аеруча бозылганын әйтеп үтәсем килә. Соңгы дистә елда хатын-кызларның нәфислеген, фәнни тел белән әйткәндә, икенчел җенси билгеләрен басым ясап күрсәтүче һәм ялангачландыручы мода буенча тегелгән кием-салым нормага әйләнде. Хәзер хатын-кызның шәрә корсагы һәм кендеге күренү гадәти, тәнгә сыланып торучы йомры формалар, җилбәгәй ачып җибәрелгән муен һәм күкрәк тирәсендәге зур изүле киемнәр кигән хатын-кызларны, әле үсеп тә җитмәгән яшь кызларның фахишәлек белән шөгыльләнүен күрү - яңалык түгел.

Дин күзлегеннән караганда ни бар соң бу турыда?


Әлбәттә, ислам дине бу гамәлләрне хупламый.

Коръәни-Кәримдә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый матур әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә. Бигрәк тә ялган сүз сөйләү, кеше канын түгү, фетнә тарату, эчүчелек, зина кылу, хәрам мал туплау гаепләнә.

Кызганычка, хәзер безнең тирә-якта шайтан котыртуы, Иблис бозыклыгы хакимлек итә. Дөнья күбрәк начар гамәлләр, көчләү-талаулар, үтерешләр, террорчылык, наркомания, эчкечелек белән тулы. Адәм баласы күңеленә Аллаһы Тәгалә тарафыннан салынган сафлыкны, әхлакый ныклыкны, мәрхәмәтлелекне ничек саклап калырга соң?..

**Алсу АЙЗАТОВА,**
**IX сыйныф укучысы.**
**Чүпрәле районы**

# ЧАЙНВОРД "УРАЗА"




*1.Изге айда һәр көн ураза тоту гамәле. 2.Ураза тоту - тәннең ...е. 3.Ураза аенда укыла торган намаз. 4.Ифтарда авыз ачу өчен татлы җимеш. 5.Ураза тотучыга Аллаһы Тәгалә тарафыннан языла торган савап. 6.Ураза ае. 7.Ураза тоткан кеше ...ен тыя. 8.Ураза тотучының таң атканчы ашау вакыты. 9.Ураза тотканда тыелган нәрсә. 10.Изге айда иңгән Изге китап. 11.Тотачак ураза турындагы уй-теләк. 12.Гыйбадәт алдыннан юыну. 13.Уразаны, гыйбадәтне тырышып үтәү - Аллаһы Тәгаләгә ... кылу. 14.Намаз укыганда мөселманнар юнәлә торган як. 15.Ифтардан соң укыла торган намаз. 16.Намазга чакырып азан әйтелә торган биек корылма. 17.Ураза тотмаска рөхсәт ителгән кеше.*

**Нияз МИНГАЛИЕВ төзеде**

## Мөфтият студентларны Ставрополь өлкәсенә юллады

2011 елның 7 августында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам университеты һәм Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәдән ике студентны Ставрополь өлкәсенә юллады. Биредә алар татар телендә ислам нигезләреннән дәрес бирәчәкләр. Студентларны Ставрополь мөфтие үзе чакырган. Алар Рамазан аеның ахырына хәтле әлеге төбәктә дин гыйлемнәре бирер, дип көтелә.

## Намаз вакытлары

| Казан | Дата | Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы (Ифтар) | Ястү һәм тәравих намазлары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| җмг | 12.08.11 | 3:08:00 | 3:38:00 | 5:09:00 | 13:02:00 | 17:59:00 | 20:27:00 | 21:57:00 |
| шмб | 13.08.11 | 3:10:00 | 3:40:00 | 5:11:00 | 13:02:00 | 17:57:00 | 20:25:00 | 21:54:00 |
| якш | 14.08.11 | 3:12:00 | 3:42:00 | 5:13:00 | 13:02:00 | 17:56:00 | 20:22:00 | 21:52:00 |
| дшм | 15.08.11 | 3:14:00 | 3:44:00 | 5:15:00 | 13:02:00 | 17:54:00 | 20:20:00 | 21:50:00 |
| сшм | 16.08.11 | 3:16:00 | 3:46:00 | 5:16:00 | 13:02:00 | 17:52:00 | 20:18:00 | 21:47:00 |
| чрш | 17.08.11 | 3:18:00 | 3:48:00 | 5:18:00 | 13:02:00 | 17:51:00 | 20:15:00 | 21:45:00 |
| пнҗ | 18.08.11 | 3:20:00 | 3:50:00 | 5:20:00 | 13:02:00 | 17:49:00 | 20:13:00 | 21:43:00 |
| җмг | 19.08.11 | 3:21:00 | 3:51:00 | 5:22:00 | 13:02:00 | 17:47:00 | 20:11:00 | 21:40:00 |
| шмб | 20.08.11 | 3:23:00 | 3:53:00 | 5:24:00 | 13:02:00 | 17:46:00 | 20:08:00 | 21:38:00 |
| якш | 21.08.11 | 3:25:00 | 3:55:00 | 5:26:00 | 13:02:00 | 17:44:00 | 20:06:00 | 21:35:00 |
| дшм | 22.08.11 | 3:27:00 | 3:57:00 | 5:28:00 | 13:02:00 | 17:42:00 | 20:04:00 | 21:33:00 |
| сшм | 23.08.11 | 3:29:00 | 3:59:00 | 5:30:00 | 13:02:00 | 17:40:00 | 20:01:00 | 21:30:00 |
| чрш | 24.08.11 | 3:31:00 | 4:01:00 | 5:32:00 | 13:02:00 | 17:39:00 | 19:59:00 | 21:28:00 |
| пнҗ | 25.08.11 | 3:33:00 | 4:03:00 | 5:34:00 | 13:02:00 | 17:37:00 | 19:56:00 | 21:26:00 |
| җмг | 26.08.11 | 3:35:00 | 4:05:00 | 5:36:00 | 13:02:00 | 17:35:00 | 19:54:00 | 21:23:00 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №1 (98) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
Мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дәнә. **Заказ:** Е-501

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 12 август, 12.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "ТатМедиа" ААҖ филиалы "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллланудан саклаfamы!**